ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О государственной гражданской службе Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 октября 2017 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 25 октября 2005 года № 106-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1; 2005, № 10 (II часть); 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 10 (II часть); 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (I часть) следующие изменения:

1) часть 1 статьи $13^1$ дополнить предложением следующего содержания: «Государственному служащему, достигшему предельного возраста пребывания на государственной службе, замещающему должность государственной службы категории «руководители» высшей группы должностей государственной службы, срок государственной службы с его согласия может быть продлен (но не свыше чем до достижения им возраста 70 лет) назначившими его на должность государственным органом или соответствующим должностным лицом.»;

2) в пункте 11 части 1 статьи 14 слова «дополнительное профессиональное образование» заменить словами «профессиональное развитие»;

3) часть 5 статьи 25 признать утратившей силу;

4) в пункте 1 части 2 статьи 34 слова «, а также дополнительное профессиональное образование государственных служащих в соответствии с программами профессионального развития государственных служащих» заменить словами «и профессиональное развитие государственных служащих»;

5) статью 36 изложить в следующей редакции:

«Статья 36. **Профессиональное развитие государственного служащего**

1. Профессиональное развитие государственного служащего направлено на поддержание и повышение государственным служащим уровня квалификации, необходимого для надлежащего исполнения должностных обязанностей, и включает в себя дополнительное профессиональное образование и иные мероприятия по профессиональному развитию.

2. Профессиональное развитие государственного служащего осуществляется в течение всего периода прохождения им государственной службы.

3. Основаниями для направления государственного служащего для участия в мероприятиях по профессиональному развитию являются:

1) решение представителя нанимателя;

2) результаты аттестации государственного служащего;

3) назначение государственного служащего на иную должность государственной службы в соответствии с пунктом 2 части 1 статьи 31 Федерального закона;

4) назначение государственного служащего в порядке должностного роста на должность государственной службы категории «руководители» высшей или главной группы должностей государственной службы либо на должность государственной службы категории «специалисты» высшей группы должностей государственной службы впервые;

5) поступление гражданина на государственную службу впервые.

4. Реализация мероприятий по профессиональному развитию государственного служащего может осуществляться:

1) посредством государственного заказа на мероприятия по профессиональному развитию государственных служащих в соответствии с законодательством Российской Федерации о контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд;

2) в рамках государственного задания в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан;

3) за счет средств государственного органа, в котором государственный служащий замещает должность государственной службы, в организации, осуществляющей образовательную деятельность по дополнительным профессиональным программам, определенной в порядке, установленном законодательством Российской Федерации о контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд.

5. Мероприятия по профессиональному развитию государственного служащего могут осуществляться за пределами территории Российской Федерации.

6. Мероприятия по профессиональному развитию государственного служащего осуществляются с отрывом или без отрыва от государственной службы.

7. Профессиональное развитие государственного служащего осуществляется в порядке, определяемом Президентом Российской Федерации.

8. Государственному служащему, участвующему в мероприятиях по профессиональному развитию, представителем нанимателя, образовательной организацией, государственным органом или иной организацией создаются условия для профессионального развития.

9. Дополнительное профессиональное образование государственного служащего включает в себя профессиональную переподготовку и повышение квалификации.

10. Дополнительное профессиональное образование государственного служащего осуществляется в организациях, осуществляющих образовательную деятельность по дополнительным профессиональным программам, в том числе на основании государственного образовательного сертификата на дополнительное профессиональное образование государственного служащего (далее – сертификат).

11. Порядок предоставления сертификата, форма сертификата, правила подачи заявления о выдаче сертификата и правила выдачи сертификата (его дубликата) устанавливаются Правительством Российской Федерации.»;

6) статью 37 изложить в следующей редакции:

«Статья 37. **Государственный заказ на мероприятия по профессиональному развитию государственных служащих**

1. Государственный заказ на мероприятия по профессиональному развитию государственных служащих на очередной год включает в себя:

1) государственный заказ на дополнительное профессиональное образование государственных служащих, в том числе за пределами территории Российской Федерации;

2) государственный заказ на иные мероприятия по профессиональному развитию государственных служащих.

2. Формирование указанного государственного заказа осуществляется органом по управлению государственной службой на основе заявок государственных органов с учетом функций государственных органов и их специализации, а также с учетом профессионального образования по должностям государственной службы, замещаемым в этих государственных органах.

3. Государственный заказ на мероприятия по профессиональному развитию государственных служащих, включая его объем и структуру, утверждается Кабинетом Министров Республики Татарстан с учетом положений настоящей статьи.»;

7) в пункте 13 части 1 статьи 41 слова «дополнительного профессионального образования» заменить словами «профессионального развития».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
13 ноября 2017 года
№ 78-ЗРТ

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $13^1$ статьяның 1 өлешендә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яшенә җиткән, дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары төркеменең “җитәкчеләр” категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә дәүләт хезмәте чоры аның ризалыгы белән әлеге дәүләт хезмәткәрен вазыйфага билгеләп куйган дәүләт органы яисә тиешле вазыйфаи зат тарафыннан озайтылырга мөмкин (әмма ул 70 яшькә җиткәнчегә кадәр).”;

2) 14 статьяның 1 өлешендәге 11 пунктында “өстәмә һөнәри белем алырга” сүзләрен “һөнәри үсешкә” сүзләренә алмаштырырга;

3) 25 статьяның 5 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

4) 34 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында “, шулай ук дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше программалары нигезендә дәүләт хезмәткәрләренә

өстәмә һөнәри белем бирү" сүзләрен "һәм дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше" сүзләренә алмаштырырга;

5) 36 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"36 статья. **Дәүләт хезмәткәренең һөнәри үсеше**

1. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри үсеше аның тарафыннан вазыйфаи бурычларны тиешлечә үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен тәэмин итүгә һәм арттыруга юнәлдерелгән һәм аңа өстәмә һөнәри белем алу һәм һөнәри үсеш буенча башка чаралар керә.

2. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри үсеше аның бөтен дәүләт хезмәтен узу чорында гамәлгә ашырыла.

3. Дәүләт хезмәткәрен һөнәри үсеш буенча чараларда катнашуга җибәрү өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) яллаучы вәкиленең карары;

2) дәүләт хезмәткәрен аттестацияләү нәтиҗәләре;

3) дәүләт хезмәткәрен Федераль законның 31 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә дәүләт хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләп кую;

4) дәүләт хезмәткәрен беренче мәртәбә вазыйфаи үсеш тәртибендә дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары яисә баш төркеменең "җитәкчеләр" категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасына йә дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары төркеменең "белгечләр" категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп кую;

5) гражданның беренче мәртәбә дәүләт хезмәтенә урнашуы.

4. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри үсеше буенча чараларны гамәлгә ашыру түбәндәгечә башкарылырга мөмкин:

1) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше буенча чараларга дәүләт заказы ярдәмендә;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә дәүләт заданиесе кысаларында;

3) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында расланган тәртиптә билгеләнгән өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада дәүләт хезмәткәре дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органы акчалары исәбеннән.

5. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри үсеше буенча чаралар Россия Федерациясе территориясеннән читтә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри үсеше буенча чаралар дәүләт хезмәтеннән аерылып яисә аерылмыйча башкарыла.

7. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри үсеше Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

8. Һөнәри үсеш буенча чараларда катнашучы дәүләт хезмәткәренә яллаучы

вәкиле, мәгариф оешмасы, дәүләт органы яисә башка оешма һөнәри үсеш өчен шартлар булдыра.

9. Дәүләт хезмәткәренә өстәмә һөнәри белем бирүгә яңадан һөнәри әзерләү һәм квалификацияне күтәрү керә.

10. Дәүләт хезмәткәренә өстәмә һөнәри белем бирү уку-укыту эшчәнлеген өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча, шул исәптән дәүләт хезмәткәренә өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт белем бирү сертификаты (алга таба – сертификат) нигезендә гамәлгә ашыручы оешмаларда башкарыла.

11. Сертификатны бирү тәртибе, аның рәвеше, аны бирү турында гариза тапшыру кагыйдәләре һәм сертификатны (аның дубликатын) бирү кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.";

6) 37 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"37 статья. **Дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше буенча чараларга дәүләт заказы**

1. Чираттагы елга дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше буенча чараларга дәүләт заказына түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт заказы, шул исәптән Россия Федерациясе территориясеннән читтә;

2) дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше буенча башка чараларга дәүләт заказы.

2. Күрсәтелгән дәүләт заказын формалаштыру, дәүләт органнарының функцияләрен һәм юнәлешен, шулай ук шушы дәүләт органнарында биләнә торган дәүләт хезмәте вазыйфалары буенча һөнәри белемне исәпкә алып, дәүләт органнарының заявкалары нигезендә дәүләт хезмәте белән идарә итү органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше буенча чараларга дәүләт заказы, аның күләмен һәм структурасын кертеп, әлеге статьяның нигезләмәләрен исәпкә алып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.";

7) 41 статьяның 1 өлешендәге 13 пунктында "дәүләт хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне" сүзләрен "дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсешен" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2017 ел, 13 ноябрь
№ 78-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ